**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул.Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР БАШЛЫГЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт,
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

2025 елның 28 августы 6 номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 18 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы карар, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге уставының 20 статьясы белән, территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре муниципаль берәмлегенең «Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре генераль планын раслау турында» 2011 елның 03 августындагы 24 номерлы Генераль планына үзгәрешләр кертү хакында «2023 елның 31 июлендәге 66 номерлы шәһәр Советы карары нигезендә», Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025елның 26 августындагы 7035/х номерлы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында» хаты белән **КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә;

2. Гавами тыңлаулар уздыру чорын - кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән алып нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр дип билгеләргә. Гавами тыңлаулар уздыру срогы 20 көннән дә ким була алмый.;

3. Эшче комиссия «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләүне һәм уздыруны үткәрергә;

3.1 РФ ГрК 5.1 маддәсендә каралган иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр әзерләргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 14 эш көне эчендә «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә әлеге карарның 3.1 п. күрсәтелгән хәбәрнамәне бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

3.4. Бәяләмә басылып чыккан көннән алып ике эш көне эчендә гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында, карар кабул итү өчен документлар комплекты белән биргә, Лаеш шәһәре советына хәбәр итәргә кирәк.

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-https://laishevo.tatarstan.ru/pzz-g-laishevo.htm. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән)көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Шәһәр башлыгы И.Ф.Зарипов